ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная д. 2а, д.Нижние Аты ,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Узәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35. E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**18 август 2023 ел** **№ 14**

**«Арча муниципаль районы Урта Атыавыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан автомобиль юллары буенча авыр йөкле һәм (яки) эре габаритлы автомобильләр хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 30.03.2021 ел, № 10 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм "Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"Федераль законның 18 статьясындагы аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында"28.04.2023 елгы 172-Ф номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитет карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан автомобиль юллары буенча авыр йөкле һәм (яки) эре габаритлы автомобильләр хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" Арча муниципаль районы Урта Атыавыл җирлеге башкарма комитетының 30.03.2021 ел, №10 карары белән расланган «Арча муниципаль районы Урта Атыавыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан автомобиль юллары буенча авыр йөкле һәм (яки) эре габаритлы автомобильләр хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентынына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5 пунктның 5 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыр йөкле транспорт чарасы - автомобиль юлының конструктив элементларының, аның участокларының күтәрү сәләте кимегән яки автомобиль юлының, аның участокларының якынлашу габариты үзгәргән очракта, авырлыгы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18 статьясындагы аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 28.04.2023 172-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясының 1 өлеше 2 пункты нигезендә кабул ителгән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында карар белән билгеләнгән авырлыгыннан һәм (яки) күчәренә йөкләнешеннән, йөкле яки йөксез һәм (яки) күчәренә йөкләнеше транспорт чарасының Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рөхсәт ителгән авырлыгыннан һәм (яки) күчәренә рөхсәт ителгән йөкләнештән артык булган транспорт чарасы»;

2) 1.5 пунктның 6 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эре габаритлы транспорт чарасы - автомобиль юлының конструктив элементларының, аның участокларының күтәрү сәләте кимегән очракта, габаритлары «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18 статьясындагы аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 28.04.2023 172-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясының 1 өлеше 2 пункты нигезендә кабул ителгән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында карар белән билгеләнгән габаритлардан яки йөкле яки йөксез габаритлары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән рөхсәт ителгән габаритлардан артып киткән транспорт чарасы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова